| | |
|---|---|
| СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ШИЛАНГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 24.04.2024 ел | № 37-211 |

с. Шеланга

Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең
2023 ел өчен бюджеты үтәлеше турындагы хисапны раслау хакында

Шилангы авыл җирлеге башлыгы В.В.Майоровның Шилангы авыл җирлеге бюджетының 2023 елдагы үтәлеше турында хисабын тыңлап фикер алышканнан соң,

Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2023 елгы Шилангы авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турында хисапны расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.
3. Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге Советының бюджет-финанс һәм икътисади мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В. В. Майоров

Югары Ослан муниципаль
районы Шилангы авыл
җирлеге Советының
2024нче елның 24нче
апреленнән
№ 37-211 карарына
Кушымта

Шилангы авыл җирлеге бюджеты, үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып, 12 миллион 338,2 мең сум күләмендә расланган (12 миллион 798,9 мең сум), шулардан:
- үз керемнәребез 8 миллион 514 мең сум тәшкил итә, бу - 69,1%. (58 %).
- 2023елның 1 апреленә җыелган үзара салым акчалары, шул исәптән республикадан алынган дотацияләр - 1 миллион 520,05 мең сум, бу - 12,3 % (5,8 %) тәшкил итә.
- һәм 2 миллион 304,15 мең сум - дотацияләр һәм ирекле калдык чаралары, бу 18,6 % тәшкил итә (36,3 %).

Бюджетның керем өлеше, ягъни җирлекнең үз керемнәре түбәндәге салымнар хисабына формалашкан:
- физик затлар керемнәренә салым - план буенча 877 мең сум, фактта 1 360.5 мең сум җыелды, 155% ка үтәлгән;
- физик затлар мөлкәтенә салым - план 326,9 мең сум булганда, фактта 557,9 мең сум җыелды, 170,7% ка үтәлгән;
- җир салымы - план 6 372 мең сум, фактта - 5967,6 мең сум, 93,7 %ка үтәлде;
Шул исәптән җир салымы - планда 1049 мең сум булганда, фактта 1 752,6 мең сум җыйганнар, 167,1%ка башкарылган;(152,8 %).
Җир салымы Юр.затларның - план 5 323 мең сум булганда, фактта 4 215,1 мең сум җыйганнар, 79,2%ка үтәлгән.
Үз керемнәрнең гомуми күләме 103,4 % тәшкил итә.

Үз керемнәребезнең барлык статьялары буенча, бездә, юридик затларның җир салымы статьяларыннан тыш, планны арттырып үтәү бара. Бу дүртенче квартал ахырында салым хезмәтләренең оешмалар буенча яңадан эшли башлавы һәм акча кайтару белән бәйле. Авыл җирлеге Башкарма комитеты, районның финанс-бюджет палатасы белгечләре тарафыннан узган елгы салым өчен түләү буенча башкарылган эшләргә салым һәм җир салымын күчерү проценты бәйле. Шулай да җитешсезлекләр бар.

План буенча 2024 елга Җирлек бюджетының гомуми кереме 7 843,47 (8,056) миллион сум күләмендә расланган, шуларның үз керемнәре 6 781 мең сумнан артык тәшкил итә - 86% (7,9 миллион сум) - (98%) -(98%),дотацияләр - 1 миллион 062,4 мең сум -(152,47) мең сум (2 %). 2024 елга үз керемнәренең суммасы алдагы еллар белән чагыштырганда кимегән. Бюджет чыгымнары керемнәргә охшаш, ягъни дефицитсыз булып тора.

Планны төгәлләштергәннән соң бюджетның чыгым өлеше 12 миллион 338,2 мең сум күләмендә расланган, 97,8%ка үтәлгән, барлык планлаштырылган чыгымнар үтәлгән.

Хезмәт хакы һәм салымнар вакытында һәм тулы күләмдә түләнгән.

Җирлек бюджеты чыгымнарының төп маддәсе - төзекләндерү, бу эшләргә 2 638 200 сум бүлеп бирелгән. Слайдта күренгәнчә төп чыгым бу-юлларны кардан чистарту, юл кырыйларын чаптыру, коммуналь хезмәтләр, электр энергиясе өчен түләү, эре габаритлы чүп-чар чыгару, табигый чүп-чарны чистарту һ.б.
Электр энергиясе өчен 2 212 745 сум тотылган.

(2 211 340) сум, шул исәптән су суырту 989 963 сум (883 695,91) мең сум,

авыл мәдәният йортының электр энергиясе (нигездә җылыту) 649 121 сум (736 513 сум),

Урамнарны яктырту өчен түләү өчен -512 108 сум.

(591 130,58 мең сум)-53826 квт, (узган ел 75447 кВт).

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлеге башлыгы
-
-
В. В. Майоров